Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы

КАРАРЫ

**08.11.2021 ел** **№ 68**

**Кама Тамагы муниципаль районының 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында**

Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары М.Х. Хәбибуллова чыгышын тыңлап фикер алышканнан соң «Кама Тамагы муниципаль районының 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 елларның планлы чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы турында», Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына районның социаль-икътисадый үсеш фаразының төп күрсәткечләрен расларга (1 нче кушымта).
2. Муниципаль районның башкарма комитетына, көчләрне сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләмнәрен арттыруны тәэмин итүгә, халыкның тормыш шартлары яхшыруга юнәлтеп, муниципаль районның комплекслы социаль-икътисадый үсешен тәэмин итәргә.
3. Җирле үзидарә органнарына, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләргә финанс-җитештерү эшчәнлегенә нигез итеп 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына социаль-икътисадый үсешнең фараз күрсәткечләрен 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе** **Н.А.Вазыйхов**